Татарстан Республикасы «Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлеге һәм аның составына керә торган Мәмәшир авыл җирлеге муниципаль берәмлеге чикләрен Киров өлкәсе чиге белән чиктәш җирдә Татарстан Республикасы чигенә тәңгәлләштерү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә

5.12.2025

Гавами тыңлаулар үткәрү урыны: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Кукмара районы, Мәмәшир ав., Яшьләр ур., 29Б (Мәмәшир авыл җирлеге башкарма комитеты бинасы).

Гавами тыңлауларны үткәрү датасы һәм вакыты: 5 декабрь, 2025 ел. 09 сәг. 00 мин.

Гавами тыңлаулар үткәрү инициаторы: Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге башлыгы

Гавами тыңлаулар уздыру өчен нигез: «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге башлыгының «Татарстан Республикасы «Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чикләрен туры китерү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында» 2025 елның 10 ноябрендәге 3 номерлы карары.

Гавами тыңлауларда каралган мәсьәләнең исеме: Татарстан Республикасы «Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлеге һәм аның составына керә торган Мәмәшир авыл җирлеге муниципаль берәмлеге чикләрен Киров өлкәсе чиге белән чиктәш җирдә Татарстан Республикасы чигенә тәңгәлләштерү.

Гавами тыңлаулар турында халыкка хәбәр итү: Гавами тыңлаулар уздыру турында мәгълүмати хәбәр (Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге башлыгының 2025 ел ның 10 ноябрендәге 3 номерлы карары):

- Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында, Мәмәшир авылы торак пункты территориясендә Яшьләр ур., 29Б й. урнашкан мәгълүмат стендларында, шулай ук Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Гавами тыңлауларда катнашучылар саны турында белешмәләр: 36 кеше.

Гавами тыңлауларда каралган мәсьәлә буенча Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлегендә яшәүчеләрдән язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кермәде.

Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча карар кабул ителде:

1. Татарстан Республикасы «Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлеге һәм аның составына керә торган Мәмәшир авыл җирлеге муниципаль берәмлеге чикләрен Киров өлкәсе чиге белән чиктәш җирдә Татарстан Республикасы чигенә тәңгәлләштерү мәсьәләсен хупларга.

2. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге Советына Татарстан Республикасы «Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлеге һәм аның составына керә торган Мәмәшир авыл җирлеге муниципаль берәмлеге чикләрен Киров өлкәсе чиге белән чиктәш җирдә Татарстан Республикасы чигенә тәңгәлләштерүгә халыкның ризалыгын белдерүне тәкъдим итәргә.

Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турындагы бәяләмә Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында, Мәмәшир авылы торак пункты территориясендә Яшьләр ур., 29Б й. урнашкан мәгълүмат стендларында, шулай ук Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарылырга тиеш.

Мәмәшир авыл җирлеге башлыгы — И.Г.Әхмәтҗанов

ОГРН 1021607753012
ИНН 1623001702